**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 29 ноябрендәге 4947 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүче муниципаль учреждениеләрнең һәм социаль-мәдәни өлкә учреждениеләренең оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәтләрнең хезмәткәрләренә 2025 елның 1 гыйнварыннан хезмәт хакын күтәрү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтә торган муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтадагы «Хезмәткәрләрнең окладын формалаштыру тәртибе» дигән II бүлекнең 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1 нче таблица

**Оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итүче җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәтләрдәге хезмәткәрләрнең вазифалары һәм вазифаи окладлары исемлеге**

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Бухгалтер | 26800 |
| 2 | Документлар белән эшләүче белгеч | 26800 |
| 3 | Инженер | 26800 |
| 4 | Җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча белгеч | 26800 |
| 5 | Икътисадчы | 26800 |

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 6 | Әйдәүче бухгалтер | 28500 |
| 7 | Әйдәүче бухгалтер-ревизор | 28500 |
| 8 | Документлар белән эшләүче әйдәүче белгеч | 28500 |
| 9 | Әйдәүче инженер | 28500 |
| 10 | Әйдәүче инженер-программист | 28500 |
| 11 | Әйдәүче белгеч | 28500 |
| 12 | Кадрлар буенча әйдәүче белгеч | 28500 |
| 13 | Җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәүче белгеч | 28500 |
| 14 | Әйдәүче икътисадчы | 28500 |
| 15 | Әйдәүче эксперт | 28500 |
| 16 | Әйдәүче юрисконсульт | 28500 |
| 17 | Сатып алулар буенча өлкән белгеч | 28500 |
| 18 | Сектор мөдире | 32500 |
| 19 | Төркем башлыгы урынбасары/бүлек башлыгы урынбасары | 32500 |
| 20 | Төркем башлыгы/бүлек башлыгы | 36793 |
| 21 | Баш бухгалтер урынбасары | 36793 |
| 22 | Баш бухгалтер | 42300» |

1.2. 1 номерлы кушымтадагы «Хезмәткәрләрнең окладын формалаштыру тәртибе» дигән II бүлекнең 2 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2 нче таблица

**Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтә торган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазифалары атамалары һәм вазифаи окладлары исемлеге**

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Администратор | 26800 |
| 2 | Архивариус | 26800 |
| 3 | Бухгалтер | 26800 |
| 4 | Инженер | 26800 |
| 5 | Әйдәүче бухгалтер | 28500 |
| 6 | Документлар белән эшләүче әйдәүче белгеч | 28500 |
| 7 | Әйдәүче инженер | 28500 |
| 8 | Әйдәүче инженер-программист/әйдәүче белгеч | 28500 |
| 9 | Әйдәүче инженер-смета төзүче | 28500 |
| 10 | Сатып алулар буенча әйдәүче белгеч | 28500 |
| 11 | Кадрлар буенча әйдәүче белгеч | 28500 |
| 12 | Әйдәүче икътисадчы | 28500 |
| 13 | Әйдәүче эксперт | 28500 |
| 14 | Әйдәүче юрисконсульт/әйдәүче юрисконсульт-эксперт | 28500 |
| 15 | Бүлек башлыгы урынбасары | 30115 |

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 16 | Сектор мөдире/баш белгеч | 31175 |
| 17 | Сатып алулар (контракт хезмәте) учреждениесе бүлекчәсе җитәкчесе/хезмәт башлыгы | 32500 |
| 18 | Бүлек башлыгы | 32500 |
| 19 | Участок башлыгы/хезмәт башлыгы | 32500 |
| 20 | Баш инженер | 37060 |
| 21 | Директор урынбасары | 37060 |
| 22 | Директорның беренче урынбасары | 37060 |
| 23 | Директор/идарәче директор | 44825» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүне бюджет классификациясенең тиешле бүлекләре буенча билгеләнгән тәртиптә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**